ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 февраль 2021 ел. Иске Тәрбит ав. № 2

«Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Иске Тәрбит авыл жирлеге»
муниципаль берәмлегендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә
курсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау
турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-03 номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымталарга туры китереп, 6424,98 сум күләмендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл жирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә курсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы 2 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://styaberdin-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл жирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» һәм бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

В.Г.Тимофеев

Иске Тәрбит авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021 е. «08» февраль
2 номерлы карарына
1нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә курсәтелә торган хезмәтләр бәясе**

| **Хезмәтләр исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2756,48 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 737,94 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2930,56 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

Иске Тәрбит авыл жирлеге
Башкарма комитетының
2021 е. «08» февраль
2 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Иске Тәрбит авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе.**

| **Хезмәтләр исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе** ***(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | 346,53 |
| 3. Мәет жирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2409,95 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 737,94 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2930,56 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |